ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

«27» апрель 2020 ел № 321

**2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планын раслау турында**

2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш чыганаклар эзләү максатыннан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән 2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планын расларга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ФБП" МКУга 2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын экономияле һәм сакчыл тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планын тормышка ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының 27 апрель 2020 ел, №321
карары белән расланган

**2020 елга Арча муниципаль районында бюджет чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын сакчыл һәм экономияле тоту, бюджетка түләүләр буенча бурычларны киметү, бюджеттан тыш өстәмә чыганаклар эзләү буенча чаралар планы**

| | Чараның исеме | Җаваплы башкаручы | Гамәлгә ашыру срогы | Үлчәү берәмлеге | Финанс бәясе - мең сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 ел |
| **1.** | **Салым һәм салым булмаган керемнәрне арттыру чаралары** | | | | |
| 1.1. | Салым һәм җыемнарны өстәмә мобилизацияләү, шул исәптән салым базасын киңәйтү хисабына | ТР берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү чараларын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссия | ел дәвамында | мең сум | 80,0 |
| 1.2. | Физик затлар керемнәренә салымның кимү сәбәпләрен анализлау һәм шуның белән бәйле рәвештә физик затлардан милек салымнарын | ТР берләштерелгән бюджетына | атна саен | әйе/юк | әйе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | мобилизацияләү | салымнар буенча бурычларны киметү чараларын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссия | | | |
| 1.3. | Мәшгульлекне легальләштерү буенча чаралар үткәрү | Арча муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алар хезмәтеннән файдалану мәсьәләләре буенча ведомствоара Комиссия | атна саен | мең сум | 90,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.4. | Салым булмаган керемнәр күләмен арттыру, шул исәптән муниципаль берәмлекләр милкенә арендага бирелә торган мөлкәт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвенең нәтиҗәле ставкаларын билгеләү чараларын үткәрү исәбенә дә. Муниципаль милектәге мөлкәтне инвентаризацияләүне дәвам итү:<br>-муниципаль мөлкәтне тоташ исәпкә алуны гамәлгә кертү;<br>-файдаланылмаган (хуҗасыз) мөлкәтне ачыклау һәм аны нәтиҗәле файдалану юнәлешләрен билгеләү;<br>- аренда түләве яки вакытлыча файдалануга тапшырган өчен башка түләү рәвешендә алына торган керемнәрне арттыру максатыннан арендага бирелә торган мөлкәтнең исемлеген билгеләү һәм раслау;<br>- муниципаль учреждениеләрнең файдаланылмый торган төп фондларын ачыклау һәм аларны сату яки арендага бирү буенча тиешле чаралар күрү. | Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | ел дәвамында | мең сум | 230,0 |
| 1.5. | Күчемсез мөлкәт объектларын, җир кишәрлекләрен дә кертеп, салым әйләнешенә кертү, шул исәптән:<br>күчемсез милек объектлары турында мәгълүматларны төгәлләштерү; күчемсез милек объектларының дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен актуальләштерү; мәгълүмат алмашу кысаларында җир | Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | ел дәвамында | мең сум | 130,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кишәрлекләре һәм башка күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр бирү; муниципаль җир контроле үткәрү. Җир кишәрлекләре һәм башка күчемсез мөлкәт хуҗаларын ачыклау һәм аларны салым салуга җәлеп итү, физик затлар тарафыннан җир кишәрлекләренә һәм мөлкәткә хокукларны рәсмиләштерүдә ярдәм итү. | | | | |
| 1.6. | Җирле үзидарә органнары белән муниципаль берәмлектә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хокук саклау органнары белән керемнәр җыюны арттыруга юнәлдерелгән чараларны үтәү буенча ведомствоара хезмәттәшлекне көчәйтү. | ТР берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү чараларын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссия | атна саен | мең сум | 240,0 |
| 1.7. | Физик затларның милек салымнарын мобилизацияләү буенча чаралар үткәрү. | ТР берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү чараларын гамәлгә ашыру буенча | атна саен | мең сум | 340,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ведомствоара комиссия | | | |
| 1.8. | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны киметү чаралары үткәрү | ТР берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычларны киметү чараларын гамәлгә ашыру буенча ведомствоара комиссия | атна саен | мең сум | 70,0 |
| **2.** | **Чыгымнарны оптимальләштерү чаралары** | | | | |
| **2.1.** | **Муниципаль хезмәт** | | | | |
| 2.1.1 | Россия Федерациясе законнарында, Арча муниципаль районының норматив документларында каралган очраклардан тыш, җирле үзидарә органнары санын арттырмау | Җирле үзидарә органнары | даими | % | 0,0 |
| 2.1.2 | Җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнар нормативларын үтәү | Җирле үзидарә органнары | даими | әйе/юк | әйе |
| **2.2** | **Бюджет челтәрен оптимальләштерү** | | | | |
| 2.2.1 | 2020 елга Арча муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе | 2020 ел | мең сум | 2553,9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.2. | Бюджет учреждениеләренең бюджеттан тыш эшчәнлегеннән кергән керемнәр хисабына чыгымнар күләмен арттыру, шул исәптән бюджет учреждениеләре тарафыннан муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдаланудан кергән керемнәр хисабына | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, ОДМСТ | 2020 ел | мең сум | 277,4 |
| 2.2.3. | Билгеләнгән срокта район бюджетына муниципаль биремне үтәүгә муниципаль хезмәтләр (эшләр) күләменең тиешле күрсәткечләренә ирешмәгән күләмдәге субсидияләрне кире кайтаруны тәэмин итү | Муниципаль бюджет учреждениеләре | 2020 ел | әйе/юк | әйе |
| 2.2.4 | Энергияне сак тоту һәм җылылык-энергия ресурсларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру | Җирле үзидарә органнары, муниципаль казна һәм бюджет учреждениеләре | ай саен | әйе/юк | әйе |
| 2.3 | **Муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | |
| 2.3.1 | Конкурентлык юлы белән процедуралар үткәрү нәтиҗәсендә бюджет учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга чыгымнарны оптимальләштерү | Башкарма комитет аппаратының икътисад һәм финанс бүлеге, муниципаль бюджет учреждениеләре | даими | мең сум | 150,0 |
| 2.3.2 | Сатып алуларның нигезле булуын, башлангыч (иң югары) контрактларның бәяләрен, сатып алына торган товарның комплектлылыгын, аның техник тасвирламаларын контрольдә тоту | Башкарма комитет аппаратының икътисад һәм финанс бүлеге | даими | әйе/юк | әйе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.4 | **Инвестиция чыгымнарын, юридик затларга субсидияләрне һәм дебитор бурычларын оптимальләштерү** | | | | |
| 2.4.1 | Дебитор бурычларын киметү планы барлыкка килү сәбәпләрен анализлау һәм кабул итү | Җирле үзидарә органнары, муниципаль казна һәм бюджет учреждениеләре | ай саен | мең сум | 600,0 |
| 2.4.3 | Юридик затларга субсидияләрнең аерым төрләрен оптимальләштерү. Юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен камилләштерү, субсидия алу өчен барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар буенча бурычлар булмауны мәҗбүри шарт итеп кую | Башкарма комитет | квартал саен | әйе/юк | әйе |